ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.03.2025 г. Заинск № 102

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 11 ноябрендәге 592 номерлы «2025 елга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы мәгариф оешмаларында укучыларны кайнар тукландыру бәясен билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль яклангнлык дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән чаралар күрү максатларында һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 11 ноябрендәге 592 номерлы «2025 елга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы мәгариф оешмаларында укучыларны кайнар тукландыру бәясен билгеләү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2. пунктта **«сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар статусына ия инвалид балаларга»** сүзләреннән соң **«инвалид балалар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән статусыннан башка»** сүзләрен өстәргә;

1.2. 1.3. пунктында **«сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар статусына ия инвалид балаларга»** сүзләреннән соң **«инвалид**

**балалар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән статусыннан башка "** сүзләрен өстәргә.»;

1.3. 1.4. пунктта **«махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булганнарга»** сүзләреннән соң **«яисә Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция барышында бурычларны үтәгәндә инвалидлык алган яки Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашкан хәрби хәрәкәтләр ветераннарына"** сүзләрен өстәргә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42